**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2008 елның 31 декабрендәге ПУ-713 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 31 октябрендәге ПУ-688 номерлы, 2013 елның 26 декабрендәге ПУ-1276 номерлы, 2014 елның 1 сентябрендәге ПУ-829 номерлы, 2016 елның 23 декабрендәге ПУ-1193 номерлы һәм 2017 елның 29 декабрендәге ПУ-1174 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.


**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 20 гыйнвар
№ ПУ-37

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның « 20 » гыйнварындагы
ПУ- 37 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы структурасы**




___